РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Сухояшского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Сукаеш авыл җирлеге
башкарма комитеты

ул. Школьная, д. 4-2,
Азнакаевский район, с.Большой
Сухояш, 423325, тел./факс
(885592)34-6-16 E-mail:
Suho.Azn@tatar.ru

Мәктәп ур.,4-2 йорт, Азнакай
районы, Зур Сукаеш авылы, 423325
тел./факс (885592)34-6-16
E-mail: Suho .Azn@tatar.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

"31" октябрь 2022 ел № 29

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьяларына һәм 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга таянып, Сукаеш авыл җирлеге башкарма комитетының җирдән файдалану һәм төзелеш эшләре алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе бәяләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советы карар итә:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 февралендәге 4 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (29.11.2016 ел №23, 05.09.2017ел №13, 11.09.2017ел №16, 18.07.2018ел № 17, 11.09.2018ел № 23, 10.10.2018ел № 30, 12.03.2019ел № 5, 19.02.2020ел № 4, 11.08.2021 ел № 16, 18.04.2022ел №13номерлы карарлар редакциясендә) үзгәрешләр кертү проектын әзерләргә керешергә

1.1 Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында

- Азнакай муниципаль районы, Зур Сукаеш авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, 16:02:120101:148 кадастр номерлы, 1178,0 кв.м мәйданлы җир кишәрлеген Ж1 индивидуаль торак төзелеше зонасыннан ОД1 күп функцияле иҗтимагый-эш зонасына үзгәртергә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен башкару тәртибен һәм срокларын билгеләргә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatar.ru.//

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык З.Җ.Закирова

Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге башкарма комитет карарына
1 нче кушымта
31октябрь 2022ел №29

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сукаеш авыл җирлеге» җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында муниципаль берәмлек проектын әзерләү эшләрен башкаруның якынча сроклары**

| N | «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү эшләрен уздыру тәртибе | Эшләрне башкару вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект әзерләү эшләрен оештыру. | 2022 елның IV кварталы |
| 2.<br>2.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең шәһәр төзелеше регламентларына үзгәрешләр кертү, җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын килештерүдә катнашучы хезмәтләрнең һәм ведомстволарның искәрмәләренә шәрехләр әзерләү. | 2022 елның IV кварталы |
| 3.<br><br>3.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча фикер алышу.<br>Ачык тыңлаулар үткәрү.<br>Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге башлыгына Азнакай муниципаль районының «Сукаеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектын һәм аңа карата мәҗбүри кушымталарны (ачык тыңлаулар беркетмәсе һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә) авыл җирлеге Советына раслау яисә кире кагу өчен җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын җибәрү турында карар кабул итү өчен, аны кабат тәкъдим итү көнен күрсәтеп, эшләп бетерерү турында карар кабул итү өчен юлларга. | 2022 елның IV кварталы |